11. I тур 2023 елның 1 мартында МББУда үткәрелә.

1 урынны алган катнашучының конкурс чыгышын видеога яздырырга (h264, mp4 яки mpeg2 форматы), сылтама булдырырга һәм 2023 елның 10 мартына кадәр срокта балаларны туган телгә өйрәтү буенча тәрбиячеләрнең методик берләшмәсе җитәкчесенең электрон адресына җибәрергә кирәк. Балаларны туган телгә өйрәтү буенча тәрбиячеләрнең методик берләшмәләре җитәкчеләре, 2023 елның 14 мартына кадәр срокта, конкурсантларның видеоязмаларына сылтамалар белән заявкаларның гомуми исемлеген Башкарма комитет мәгариф идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлегенә тапшырырга тиеш.

Катнашучының конкурс чыгышы визит карточкасын һәм сәнгать номерын үз эченә алырга тиеш, монда катнашучы индивидуаль формада яки тәрбияләнүчеләр катнашында үзе, гаиләсе турында, татар теленә мөнәсәбәте, үзенең шөгыльләре, шулай ук татар халкының тарихи, рухи традицияләре һәм мәдәнияте турында сөйли (визит карточкасының һәм сәнгать номерының дәвамлылыгы 3 минутка кадәр). Визит карточкасын күрсәткәндә зурларның катнашуы рөхсәт ителми. Сәнгать номеры татар телендә башкарылырга тиеш. Сәнгать номерын күрсәткәндә зурларның катнашуы рөхсәт ителми.

Видеороликларда түбәндәгеләр күрсәтелгән мәгълүмат булырга тиеш:

1) белем бирү оешмасының исеме;
2) конкурсның исеме;
3) авторның фамилиясе, исеме;
4) конкурс эшенең темасы.

12. II тур оештыру комитеты тарафыннан конкурсантларның чыгышлары видеороликларын карау юлы белән 2023 елның 15 мартыннан 2023 елның 17 мартына кадәр үткәрелә.

2023 елның 16 мартында оештыру комитеты 1-42 нче МББУ катнашучыларының конкурс чыгышлары видеороликларын карый;

2023 елның 17 мартында оештыру комитеты 43-86 нчы МББУ катнашучыларының конкурс чыгышлары видеороликларын карый;

2023 елның 20 мартында оештыру комитеты 87-131 нче МББУ катнашучыларының конкурс чыгышлары видеороликларын карый.

Конкурсның II туры нәтиҗәләре буенча МББУның һәр төркеменнән 10 катнашучы сайлап алына.

13. Балаларның чыгышларын бәяләүнең төп критерийлары (5 баллы система буенча):

1) татар телен белү;
2) сәхнәдә үзен тота белү;
3) актерлык осталыгы һәм сәхнә сөйләме дәрәҗәсе;
4) индивидуальлек;
5) музыканың, җырның, шигырьнең эчтәлеге балалар яшенә туры килү;
6) концерт номерларының әзерлеге һәм тамашалыгы;
7) костюмнарның эстетик ягы.

Конкурсантларның чыгышларын бәяләгән вакытта, номерлар башкарганда файдаланылган реквизит бәяләнмәячәк.

14. Гомуми рейтингта иң күп балл җыйган 20 катнашучы III турга уза, ул 2023 елның 27 мартыннан 2023 елның 30 мартына кадәр үткәрелә, катнашучыларның татар телен белү дәрәҗәсе диалог уены үткәрү юлы белән бәяләнә.

III тур җиңүчеләре – 5 малай һәм 5 кыз – конкурс финалында катнашу өчен тәкъдим ителә. Конкурсның финалисты үзе турында презентация һәм сәнгать номеры тәкъдим итә.

15. Конкурсның финалы 2023 елның 12 апрелендә Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы татар дәүләт драма театрында узачак.

